ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

18 март 2026 ел

**КАРАР**

№ 2662

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2025 елның 5 декабрендәге 10208 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 219-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2025 елның 5 декабрендәге 10208 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»;

2) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 статьясы, Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү кодексының 25 статьясы, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.13 статьясы, «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 109.2 статьясы нигезендә»;

3) 1 пунктта 2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4) 2 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 20 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.Ә. Сәлимхановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов